**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 июнь № 369

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 декабрь, 980 нче, 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче, 2015 ел, 24 декабрь, 967 нче, 2015 ел, 30 декабрь, 1021 нче, 2016 ел, 1 март, 125 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Программага кушымтада:

4 таблицаның 2 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. Республикада эксплуатацияләнә торган автотранспорт чараларын | ТР Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм күрсәтү програм- | Автотранспорт чараларын ГМЯ куллануга | 1 500 | 375 000 | 0 | 75 000 | 300 000». |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ГМЯ кулланууга яңадан җиһазлау | маларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча), «Газпром газмотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) | яңадан җиһазлау, берәмлек | | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков